Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлегенең Чуаш Борнае авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 21 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 19 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чуаш Борнае авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Кичүе авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлегенең Чуаш Борнае авылында гражданнар җыенының 2019 елның 21 ноябрендәге 4 номерлы беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге составына керүче Чуаш Борнае авылындагы гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлар, 80 яшьтән өлкәнрәк өлкән яшьтәге затлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме: алардан:

- урам яктырткычлары өчен кирәкле материал сатып алу һәм урамнарны яктырту өчен кулланылган энергия чыгымнарына түләүгә-100 сум;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, су челтәрләрен реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен башкару, кулланылган электр энергиясе өчен түләү, суны лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләүгә-100 сум;

- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш сибү, тигезләү, юллар салу өчен төзелеш материаллары сатып алу, чабу, кардан чистарту), МТЗ-82 тракторына хезмәт күрсәтү, трактор өчен ягулык – майлау материаллары сатып алуга - 350 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу, каты көнкүреш калдыклары полигонын һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне рекультивацияләү – 50 сум сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлар, 80 яшьтән өлкәнрәк өлкән яшьтәге затлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- урам яктырткычлары өчен кирәкле материал сатып алу һәм урамнарны яктырту өчен кулланылган энергия чыгымнарына түләүгә-100 сум;

- урамдагы су белән тәэмин итү системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, су челтәрләрен реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен башкару, кулланылган электр энергиясе өчен түләү, суны лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләүгә-100 сум;

- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш сибү, тигезләү, юллар салу өчен төзелеш материаллары сатып алу, чабу, кардан чистарту), МТЗ-82 тракторына хезмәт күрсәтү,трактор өчен ягулык – майлау материаллары сатып алуга - 350 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу, каты көнкүреш калдыклары полигонын һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне рекультивацияләүгә -50 сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Чуаш Борнае авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Чуаш Борнае авыл җирлеге башлыгы: И. Г. Зарипов